# “Күңелле авыл“ 5 нче төркем



*Уку –тәрбия эшләре “Туганнан алып мәктәпкәчә яшькә кадәр” программасы буенча алып барыла.*

*Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә.*

***Валиуллина Зөлфия Раббаниевна тәрбияче***

***Хайруллина Миляуша Закариевна тәрбияче***

***Нигаматьянова Зилә Әдиповна тәрбияче ярдәмчесе***







***Һәрбер иртә бакчада түбәндәге шигырь юллары белән башлана***




***Хәерле иртә, агачлар...***
***Хәерле иртә, кошлар.***
***Хәерле иртә, табигать***
***Хәерле иртә, дуслар!***

## *Балалар психик үсешенең яшь үзенчәлекләре*

### *3-4 яшьлекләр*

3-4 яшьлек балаларның карашлары акрынлап гаилә чикләрен үтеп чыга башлый. Ситуациялардән тыш аралашулар барлыкка килә. Олы кеше аның өчен гаилә әгъзасы гына түгел, ә аерым ижтимагый функция башкаручыга да әйләнә.Баланың да ижтимагый функция башкарасы килү теләге аның реаль мөмкинлекләре белән каршылыкка китерә. Бу каршылык мәктәпкәчә яшьтәгеләр эшчәнлегенең төп төре булган **уен** аша чишелә.

**Шартлылык** уенның төп үзенчәлеге булып тора: бер төрле предметлар белән эш-хәрәкәтләр аларның башка предметлар белән икенче эш-хәрәкәтләргә каравын күз алдында тота. Уенчыклар һәм аларны алмаштыручы предметлар белән эш-гамәлләр кече яшьтәге балалар уенының төп эчтәлеген тәшкил итә.Кече яшьтәгеләр 1-2 рольле яки гади, җыйнак сюжетлы уеннар белән канәгатьләнәләр.

Бу яшьтә кагыйдәле уеннар формалаша гына башлый әле.

Баланың сурәтләү эшчәнлеге формалаша гына. График образлар гади, ярлы. Сурәтләрдә детальләр бик аз. Балалар инде төсләрне куллана беләләр.Кул чуклары хәрәкәтен үстерүдә әвәләүнең әһәмияте бик зур.Кече яшьтәгеләр олылар житәкчелегендә әвәләп гади предметлар ясарга сәләтле.

Кисеп ябыштыру кабул итү эшчәнлеге (зиһенле алуны) үстерүгә уңай йогынты ясый.

Бу яшьтә иҗади күзаллау сәләте үсә башлый. Балалар уен вакытында бер төрле объектларны башкаларын алыштыручы сыйфатында кулланалар.

Балалар арасындагы мөнәсәбәтләр бигрәк тә уен эшчәнлегендә ачык чагыла. Алар күбрәк бергәләшеп түгел, ә янәшә уйнауны өстен күрәләр. Ләкин бу чорда балалар арасында сайлап алуга корылган мөнәсәбәтләр өстенлек итә. Низаглар күбесенчә уенчыклар аркасында килеп чыга.Бу яшьтә балалар аңлы рәвештә үз тәртипләре белән идарә итә белмиләр, күбесенчә баланың тәртибе ситуациягә бәйле. Шуның белән бергәттән, балаларның, олылар әйтүе буенча, ниндидер теләкләрен чикләү очраклары да күзәтелә. Үз-үзен бәяләү сыйфаты үсә башлый.Җенси аерымлыкларның да үсеше күзәтелә. Бу бигрәк тә уенчыклар һәм уен сюжетларын сайлаганда (кызлар - курчак, малайлар машина сайлый) ачык чагыла

21.08.2015 13:49


СКОЗКИ
FramePicOnline.com














***Без ясаган милəш, кызыл тəлгəш…***



***Тузганак чəчəк атты...***









Безнең иҗат
Наше творчество
21.08.2015 13:47



